ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 ел, « 21 » август** **№ 43**

**Яңасала авыл җирлеге башкарма комитетның 2016 елның 28 декабрендәге «Муниципаль мәгълүмат системаларының эшчәнлеге һәм алардан файдалану тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында " 20 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2006 елның 27 июлендәге "Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында”149-ФЗ номерлы федераль законга, 2013 елның 5 апрелендәге “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар,эшләр, хезмәт күрсәтүләр, сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында“ 44-ФЗ номерлы федераль законның 4 нче статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 28 ноябрендәге "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр, сатып алу өлкәсендә төбәк һәм муниципаль мәгълүмат системаларына бердәм таләпләр турында " 1091 номерлы карарына яраклаштыру максатыннан Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР бирә:

1. Татарстан республикасы Арча муниципаль районы “Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең муниципаль мәгълүмат системаларының эшчәнлеге һәм алардан файдалану тәртибе турындагы Яңасала авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 28 декабрендәге «Муниципаль мәгълүмат системаларының эшчәнлеге һәм алардан файдалану тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" 20 нчы номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.7 пунктының 2 пунктчасының 5 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 3.7 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

“ 3) контракт системасы турында гамәлдәге Федераль законда каралган электрон документларга кул кую өчен көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (алга таба - көчәйтелгән электрон имза) куллану»;

1.3.3.7 пунктының 4 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.4. 4.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Региональ һәм муниципаль системалардан бердәм мәгълүмати

системага тапшырыла торган мәгълүмат һәм документлар контракт системасы турында Федераль законда каралган электрон имза белән имзалана.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карар игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңасала авыл
җирлеге башлыгы

Сафин А.И.